КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 апрель

г.Казань

№ 466

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре, гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, Татарстан Республикасы югары белем бирү мәгариф оешмалары, шулай ук яшь яшьтәге инвалидлар һәм аларны эшкә урнаштыруга ярдәм итү мөмкинлекләре чикләнгән затлар белән һөнәри юнәлеш эшен оештыру буенча Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәкләренең ведомствоара хезмәттәшлеге регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре, гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, Татарстан Республикасы югары белем бирү мәгариф оешмалары, шулай ук яшь яшьтәге инвалидлар һәм аларны эшкә урнаштыруга ярдәм итү мөмкинлекләре

чикләнгән затлар белән һөнәри юнәлеш эшен оештыру буенча Татарстан Республикасы халкының мәшгульлек үзәкләренең ведомствоара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2021 ел, 17 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф бүлекләренең (идарәләренең), гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының, Татарстан Республикасы югары белем бирү мәгариф оешмаларының, шулай ук Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәкләренең яшь инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар белән аларны эшкә урнаштыруга ярдәм итүдә һөнәри юнәлеш эшен оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлеге регламентына, I бүлекнең 2 бүлекчәсенең унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру процессының стандартын раслау турында» 2022 елның 25 февралендәге 82н номерлы боерыгы;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин